КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 25 август г.Казань № 630

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче, 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы, 2018 ел, 12 июль, 566 нчы, 2018 ел, 29 сентябрь, 884 нче, 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче, 2018 ел, 15 декабрь, 1138 нче, 2020 ел, 17 март, 192 нче, 2020 ел, 14 июль, 590 нчы, 2020 ел, 5 август, 656 нчы, 2020 ел, 28 декабрь, 1203 нче, 2021 ел, 7 октябрь, 959 нчы, 2021 ел, 7 декабрь, 1180 нче, 2022 ел, 12 март, 224 нче, 2022 ел, 31 октябрь, 1161 нче, 2023 ел, 16 июнь, 723 нче, 2023 ел, 26 сентябрь, 1185 нче, 2024 ел, 16 июль, 562 нче, 2024 ел, 19 август, 671 нче, 2024 ел, 9 сентябрь, 749 нчы, 2025 ел, 15 гыйнвар, 13 нче, 2025 ел, 27 март, 177 нче, 2025 ел, 3 июнь, 398 нче, 2025 ел, 11 июнь, 419 нчы, 2025 ел, 10 июль, 497 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.81 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«3.3.82. Тамаша чаралары тематикасы, аларны уздыру урыны, датасы һәм вакыты, аларга килүчеләрнең планлаштырыла торган саны, тамаша чараларының иминлеген тәэмин итү кагыйдәләре белән билгеләнә торган очракларда һәм тәртиптә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүне оештыру буенча планлаштырыла торган чаралар турында кызыксынган башка органнарга һәм учреждениеләргә аларны үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итә йә тамаша чарасы үткәрү турында кыска гына вакыт эчендә мәгълүмат алган очракта,

яисә аны үткәрү тематикасын, урынын, датасын һәм вакытын үзгәртү яисә аны юкка чыгару турында кыскача мәгълүмат алган очракта кичекмәстән хәбәр итә.».

2. Бу карар 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин